УДК 745
ББК 85.12
А 52

*Печатается по решению Ученого совета Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан*

Издание изготовлено по результатам I Республиканского конкурса-выставки произведений декоративно-прикладного искусства «Алтын кош – Золотая птица», прошедшего в галерее музея им.А.Н. Мазитова (ул. Дзержинского, 27)
с 30 августа по 30 сентября 2017 года.

**Научный редактор:**
Р. Р. Султанова, кандидат искусствоведения, заслуженный деятель искусств РТ, лауреат премии им. Баки Урманче

**Организаторы выставки-конкурса:**
Министерство культуры Республики Татарстан (РТ)
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ
Татарстанское отделение Ассоциации искусствоведов (ТатАИС)

**Кураторы выставки:**
Р. Р. Султанова, кандидат искусствоведения, заслуженный деятель искусств, лауреат премии им. Баки Урманче
Л. Ф. Фасхутдинова, заслуженный деятель искусств Республики Татарстан, заведующий музеем им. А.Н. Мазитова МБУК города Казани «Национальный культурный центр «Казань»
Л. М. Шкляева, кандидат искусствоведения, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ

**Автор-составитель:** Л. М. Шкляева
Дизайн обложки, макет, верстка, обработка изображений А.В. Булатов
Перевод на татарский язык А.К. Булатовой
Редактор, корректор А.К. Булатова

На обложке использована фотография панно «Птицы» Н. Х.Кумысниковой

Шкляева Л.М. Алтын кош – Золотая птица. Каталог выставки «Алтын кош – Золотая птица». – Казань, 2018. – 44 с.

ISBN 978-5-93091-270-8

Министерство культуры Республики Татарстан
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан
Татарстанское отделение Ассоциации искусствоведов (ТатАИС)

Л. М. Шкляева

# АЛТЫН КОШ – ЗОЛОТАЯ ПТИЦА

I Республиканский конкурс-выставка произведений современного
декоративно-прикладного искусства

Художественная обработка дерева, металла, текстиля, глины, кожи

**Каталог выставки**
**«Алтын кош – Золотая птица»**
30 августа - 30 сентября 2017 года
галерея музея им. А.Н. Мазитова (ул. Дзержинского, 27)

Казань – 2018

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Сәнгать белгечләре ассоциациясенең Татарстан бүлекчәсе

Л. М. Шкляева

# АЛТЫН КОШ – ЗОЛОТАЯ ПТИЦА

Декоратив-гамәли сәнгать әсәрләренең I Республика бәйгесе

Агачны уеп бизәкләү, металлны, тукыманы, балчыкны, күнне сәнгатьле эшкәртү

**Күргәзмә каталогы**
**«Алтын кош – Золотая птица»**
2017 ел, 30 август – 30 сентябрь
Ә.Н. Мәҗитов исемендәге музей-галереясы (Дзержинский урамы, 27)

Казан – 2018

## ПОБЕДИТЕЛИ РЕСПУБЛИКАНСКОГО КОНКУРСА ДЕКОРАТИВНО-ПРИКЛАДНОГО ИСКУССТВА «АЛТЫН КОШ – ЗОЛОТАЯ ПТИЦА» 2017 г.

## «АЛТЫН КОШ – ЗОЛОТАЯ ПТИЦА» ДЕКОРАТИВ-ГАМӘЛИ СӘНГАТЬ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ РЕСПУБЛИКА БӘЙГЕСЕНДӘ ҖИҢҮЧЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

Номинация: Художественная обработка металла. Реконструкция
**Гриценко Любовь Григорьевна**



«Металлны сәнгатьчә эшкәртү. Реконструкция» номинациясе
**Гриценко Любовь Григорьевна**

Номинация: Ювелирное искусство
Авторский проект
Номинация: Художественная обработка дерева. Авторский проект
**Ахметов Ринат Хаметлатифович**



«Зәркәнчелек сәнгате. Автор проекты» номинациясе
«Агачны кисеп, уеп бизәкләү. Автор проекты» номинациясе
**Әхмәтов Ринат Хәмитлатыйф улы**

Номинация: Художественная обработка кожи. Авторский проект
**Колесова Анастасия Николаевна**



«Күнне сәнгатьчә эшкәртү. Автор проекты» номинациясе
**Колесова Анастасия Николаевна**

Номинация: Керамика. Авторский проект
**Кузьминых Нина Васильевна**



«Керамика. Автор проекты» номинациясе
**Кузьминых Нина Васильевна**

Номинация: Батик. Авторский проект
**Барышева Диля Рашидовна**



«Батик. Автор проекты» номинациясе
**Барышева Диләә Рәшит кызы**

## ПРОДОЛЖАЯ ТРАДИЦИИ: РЕЗУЛЬТАТЫ I РЕСПУБЛИКАНСКОГО КОНКУРСА-ВЫСТАВКИ «АЛТЫН КОШ – ЗОЛОТАЯ ПТИЦА»

Декоративно-прикладное искусство издревле имело огромное значение в системе татарской культуры, оставаясь ведущим направлением художественного творчества вплоть до начала XX века. Благодаря сельским народным мастерам и городским ремесленникам сохранились визуальные символы исторической памяти народа и особенности самобытного пластического языка. Произведения, отражающие мировосприятие татар, создавались в русле национальных традиций, сформированных на основе лучших образцов коллективного художественного опыта. Народное искусство у татар, развиваясь по соответствующим его содержанию законам, взаимодействовало с различными видами изобразительного искусства, перенимая стилевые приемы, свойственные определенным историческим периодам.

В сферу декоративно-прикладного искусства Татарстана в настоящее время вовлечены как подлинно народные потомственные мастера, не получившие специального образования (их число неуклонно сокращается), так и профессиональные художники. В творчестве последних проявляются стилевые особенности либо татарского, либо русского искусства, в зависимости от воплощаемого замысла, а не от национальной принадлежности мастера, что было определяющим ещё в середине XX века. На фоне относительной стабильности и устойчивости в экономическом и политическом аспектах в Татарстане первой четверти XXI века продолжает наблюдаться усиление интереса к традиционным видам татарского искусства, что поддерживается правительством Республики. Вышивка, кожаная мозаика, резьба по дереву, ювелирное дело, развиваются благодаря творчеству немногочисленных профессиональных художников и умелых ремесленников-самоучек, некоторым из которых удается создавать произведения, соответствующие уровню высокого искусства. Однако в настоящее время большинство из таких мастеров являются производителями сувениров максимально рассчитанных на сбыт и не имеющих отношения к подлинному национальному искусству. Многие профессиональные художники также хотят быть востребован-

## ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ ДӘВАМ ИТЕП: «АЛТЫН КОШ – ЗОЛОТАЯ ПТИЦА» ДЕКОРАТИВ-ГАМӘЛИ СӘНГАТЬ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ I РЕСПУБЛИКА БӘЙГЕСЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Декоратив-гамәли сәнгать татар мәдәниятендә борынгыдан зур әһәмияткә ия. XX гасыр башына кадәр ул төп сәнгать юнәлеше буларак санала. Авыл җирлегендә яшәүче кул эшләре осталары һәм шәһәр һөнәрчеләре булышлыгы белән халыкның тарихи хәтерендә визуаль символлар һәм үзенчәлекле пластик стиль сакланып кила. Уртак, коллектив сәнгать тәҗрибәсенең иң яхшы үрнәкләре нигезендә барлыкка килгән һәм милли традицияләрне гәүдәләндергән хезмәтләр халыкның дөнья күзаллауларын чагылдыралар. Татар халкында милли сәнгать аның эчтәлегенә туры килгән махсус законнар нигезендә үсеш ала, сәнгатьнең башка төрләре белән бәйләнештә булып, аерым тарихи чорга караган стиль үзенчәлекләрен үзләштерә.

Хәзерге вакытта Татарстанның декоратив-гамәли сәнгать өлкәсендә махсус белемнәре булмаган үзешчән халык осталары (кызганычка каршы, аларның саны елдан-ел кими бара) һәм профессиональ осталар иҗат итә. Соңгыларының хезмәтләрендә татар яисә рус сәнгатенең стилистик үзенчәлекләре чагылыш таба. Алар XX йөз урталарына кадәр теге яисә бу останың кайсы милләттән булуына карап түгел, ә аларның төп фактор буларак саналып килгән теләк-ниятләреннәр чыгып билгеләнә. Татарстан Республикасындагы сәяси һәм икътисади тотрыклылык шартларында татар милли сәнгатенә мөрәҗәгать итү активлаша төшә. Дәүләт тарафыннан да ярдәм күрсәтелә. Чигү, күн мозаикасы, агачны уеп бизәкләү, зәркәнчелек кебек сәнгать төрләре, аз сандагы профессиональ осталардан тыш, үзешчән һөнәрчеләр тырышлыгы белән дә үсеш ала. Әлеге осталарның кайберләре югары дәрәҗәдәге сәнгать әсәрләре барлыкка китерәләр. Шулай да соңгы вакытта күпчелек осталар чын сәнгатькә катнашы булмаган һәм сатар өчен генә ясалган сувенир продукциясе эшләп чыгара башладылар. Күп кенә профессиональ иҗатчылар, шулай ук, сувенир продукциясе базарында уңыш казану максатыннан, күпләгән сатып алучыларның ихтыяҗына исәп тоталар. Шулай итеп үзенчәлекле милли татар сәнгате хакында ялгыш күзаллаулар тарала, бу исә милли сәнгать өлкәсендә зур масштаблы проблемага әверелеп бара.

ными на рынке сувенирной продукции и намеренно подстраиваются под вкусы массового потребителя. Таким образом, широко распространяется искаженное представление о самобытном искусстве татар, что уже обретает масштабы настоящей проблемы для национальной культуры.

Для противодействия обозначенных негативных тенденций в 2017 году по инициативе Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан, при поддержке Министерства культуры Республики Татарстан, а также Татарстанского отделения Ассоциации искусствоведов (ТатАИС) был организован I Республиканский конкурс произведений декоративного искусства «Алтын кош – Золотая птица». Проект был призван содействовать развитию современного профессионального татарского декоративного искусства на основе исторически сложившихся эстетических ценностей. Были предусмотрены следующие номинации: «Авторский проект», «Реконструкция», «Сувенир» в таких видах народного искусства, как: вышивка, ткачество, керамика, ювелирное искусство, художественная обработка кожи, дерева, металла и шерсти. Намечалось привлечение внимания мастеров к аутентичным изделиям декоративно-прикладного искусства татар и побудить их к изучению музейных коллекций. Также предполагалось поддержать художников, развивающих национальное декоративное искусство, в том числе в его новых видах, таких как: батик, фарфор, эмаль и др. Министерство культуры Республики Татарстан определило вознаграждение каждому победителю в размере 15 тысяч рублей.

Основным условием конкурса было обращение к традиционным принципам татарского народного искусства: применение самобытных технических приемов, использование устойчивых орнаментальных мотивов и стилевых особенностей.

В настоящее время в тюркском мире исследуется миропонимание далеких предков, трансляция образов которого приобретает все большую актуальность. Так, для татар, синий цвет является символичным, поскольку связан с цветом неба, олицетворяющего главного бога Тенгри. С особой теплотой татары относятся к птицам, в образе одной из которых могла явиться богиня Умай. Она занимала одно из ведущих положений в тюркском пантеоне и почиталась в качестве супруги Тенгри. По поверьям Умай также воплощалась в виде цветка-трилистника, антропоморфного существа в трехрогой короне, женщинам давала знать о своем присутствии вспыхнувшими языками пламени домашнего очага. Умай считалась и богиней плодородия, стимулирующей женскую плодовитость, и хранительницей семейного счастья, и покровительницей детей. Раскрытие и осмысление образа Умай стало темой конкурса «Алтын кош – Золотая птица».

Конкурсантами стали профессиональные мастера – члены общественных творческих организаций: Союзов художников России и Татарстана, а также студенты и преподаватели Казанского государственного института культуры, Казанского художественного училища им. Н. Фешина, Казанского техникума художественных народных промыслов. Художникам предоставлялась возможность воплощения Умай либо в авторской трактовке, либо в реконструкции образов, связанных с тюркским декоративно-прикладным искусством из музейных коллекций.

В номинации «Реконструкция» были представлены работы трех мастеров (Л.Г. Гриценко, Т.В. Соловьевой и А.С.Шамсутдинова). Остальные девятнадцать участников конкурса выбрали номинацию «Авторский проект», предполагающую свободную трактовку национальных мотивов. Этническое своеобразие проявлялось в сюжетах, материалах и техниках исполнения.

Конкурсные произведения были представлены на выставке, открывшейся 30 августа 2017 года в галерее им. Амира Мазитова и длившейся до 30 сентября. В экспозицию также вошли работы, дополняющие общую картину развития тюркского декоративного искусства из Татарстана и Крыма.

На выставке демонстрировались более пятидесяти произведений двадцати двух художников. Часть из них воплотила творческие замыслы с соблюдением преемственности самобытных эстетических канонов, поддерживающих национальную идентичность. К ним относятся: вышивка З.Н. Бикташевой и Л.Ф. Фасхутдиновой, художественный текстиль Н.А. Галявиевой, резьба по дереву Р.Х. Ахметова, ювелирные изделия А.С. Шамсутдинова и Т.В. Соловьевой, кожаная мозаика Н.Х. Кумысниковой и студентов КХУ им. Н.И. Фешина – учеников А.А. Замиловой. Эти мастера, умело использующие природную фактуру материала, обрабатывают и декорируют его выработанными поколениями способами и приемами. Так профессиональные художники оказались приемниками лучших традиций национального искусства, которое они развивают в соответствующих видах творчества.

Әлеге негатив тенденцияләргә каршы чара буларак, 2017 елда Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты инициативасы белән, ТР Мәдәният министрлыгы һәм Сәнгать белгечләре ассоциациясенең Татарстан бүлекчәсе ярдәме белән «Алтын кош – Золотая птица» декоратив-гамәли сәнгать әсәрләренең I Республика бәйгесе оештырылды. Проект тарихи формалашкан, эстетик канунннар нигезендә барлыкка килгән хәзерге профессональ татар декоратив-гамәли сәнгатен үстерүгә юнәлтелгән иде. Чигү, керамика, тукучылык, зәркәнчелек, күн, агач, металл һәм йонның сәнгатьчә эшләнеше кебек сәнгать төрләре буенча түбәндәге номинацияләр аерып чыгарылды: «Автор проекты», «Реконструкция», «Сувенир». Осталар игътибарын татар халкының аутетик декоратив-сәнгате төрләренә һәм музей җыелмаларын өйрәнүгә җәлеп итү күздә тотылды. Шулай ук батик, фарфор, эмаль кебек сәнгатьнең яңа төрләрен үстерү һәм милли декоратив сәнгать өлкәсендә хезмәт куючы осталарга ярдәм йөзеннән дә оештырылды. ТР Мәдәният министрлыгы тарафыннан һәр җиңүчегә 15 мең күләмендә акчалата бүләк бирелде.

Бәйгенең төп шарты итеп татар милли сәнгатенең традицион принципларыннан –үзенчәлекле техник ысулар, орнамент мотивларының стилистик үзенчәлекләрен файдалану һ.б. билгеләнде.

Хәзерге вакытта төрки даирәдә әби-бабаларыбызның дөнья күзаллаулары, шул чор образларын торгызу актуальләшеп бара. Мәсәлән, татар халкында зәңгәр төс символик төс булып санала, ул төп Алла Тәңрене күзаллый. Шулай ук татарлар кошларга аерым җылылык белән карыйлар, төрле ышануларда Һомай алиһәсе кош сурәтендә килергә мөмкин дип санала. Ул төрки пантеонда мөһим урыннарның берсен биләп, Тәңренең хатыны буларак кабул ителә. Ышанулар буенча, Һомай алиһәсе тукранбаш чәчәге, өч таҗлы антроморф җисем образында күренергә мөмкин, хатын-кызларга ул үзенең янәшәдә булуын учакның ялкынланып китүе ярдәмендә белгертә, ди. Һомай хатын-кызның бала тудыру сәләтен стимуллаштырган, уңыш, гаилә иминлеге сакчысы, балаларны яклаучы алиһә буларак кабул ителгән. Һомай образын киңкырлы ачуны күздә тотып, конкурсның темасы да «Алтын кош» дип аталды.

Бәйгедә һөнәри осталар, Россия һәм Татарстан Рәссамнәр берлеге әгъзалары, Н. Фешин исем. Казан сәнгать училищесы, Казан халык сәнгате һөнәрләре техникумы, Казан дәүләт мәдәният институты укытучылары һәм студентлары көч сынашты. Бәйгедә катнашучыларга татар милли сәнгате традицияләрен саклау — үзенчәлекле техник ысуллар, тотрыклы бизәлеш мотивларын куллану бурычы йөкләнде. Шулай ук Һумай алиһәсен автор трактовкасында тасвирлау мөмкинлеге дә бирелде.

«Реконструкция» номинциясендә өч оста (Л.Г. Гриценко, Т.В. Соловьева, А.С. Шәмсетдинова) көч сынашты. Калган унтугыз катнашучы «Автор проекты» номинациясен сайлап алды. Әлеге номинация милли мотивларны ирекле сурәтләү мөмкинлеге бирелгәнлектән, этник үзенчәлек сюжет, материал һәм сурәтләнеш техникасында чагылыш тапты.

Әлеге күргәзмә-бәйге Әмир Мәҗитов исемендәге галереяда 30 августтан алып 30 сентябрьгә кадәр үткәрелде. Күргәзмә өчен бәйгедә катнашучыларның иң яхшы дип табылган хезмәтләре сайлап алынды. Экспозициядә шулай ук Татарстан һәм Кырымның төрки декоратив-гамәли сәнгать үсеше картинасын тулыландыручы хезмәтләр дә урын алды.

«Алтын кош – Золотая птица» күргәзмә-бәйгесендә Татарстан Республикасында иҗат итүче 22 рәссамның илледән артык хезмәте бәяләнде. Конкурста катнашкан осталарның хезмәтләрендә татар халкы милли эстетик кануннарының гасырдан-гасырга, буыннан-буынга күчә баруы, милли үзаңның камилләшүе иҗади гәүдәләнеш алган иде. Алар арасында З.Н. Бикташева белән Л.Ф. Фәсхетдинованың чигү эшләре, Н.А. Галәвиеваның сәнгатьле бизәк төшергән тукыма, Р.Х. Әхмәтовның кисеп, уеп бизәкләнгән агач эшләнмәләре, А.С. Шәмсетдинов белән Т.В. Соловьеваның зәркән әйберләре, Н.Х. Кумысникованың һәм Н. Фешин исем. Казан сәнгать училищесыннан Ә.А.Җәмилова укучыларының күн мозаикасы техникасына нигезләнеп эшләнгән хезмәтләре урын алган иде. Сәнгатькәрләр материалның табигый фактурасыннан чыгып, аны эшкәртү, бизәкләүнең буыннан-буынга күчеп сакланган ысулларын кулланалар, ягъни профессиональ осталарга милли сәнгатьнең иң яхшы традицияләрен үзләштерү һәм аны тагын да үстерү мөмкинлеге бирелде.

# ВЫШИВКА

Произведения З.Н. Бикташевой и Л.Ф. Фасхутдиновой свидетельствуют о развитии вышивального дела в декоративном искусстве татар. Источником для творческих поисков современных мастериц послужили образцы самобытной вышивки, датируемые серединой XIX – началом XX в., находящиеся в музейных и частных коллекциях. В данных собраниях сохранились калфаки, отделанные золотным шитьем, бисером или речным жемчугом, а также редко встречающиеся головные уборы с рельефными цветочными формами из разноцветных лент в ушковой технике, а также декоративный текстиль, традиционно использующийся в оформлении интерьера татарских жилищ, вышитый в техниках «тамбур», «несчетная односторонняя гладь» и ковровый шов. Изделия мастеров прошлого были расшиты растительно-цветочными узорами в асимметричных композициях, решенных в контрастной яркой палитре, создающей праздничное настроение.

Искусство вышивки в стране угасало в периоды Октябрьской революции, Гражданской и Отечественной войн, но сохранилось, благодаря традиции приготовления приданого. Новым всплеском интереса к вышивке характеризуются вторая половина 1950-х и 1960-е годы. Повсеместно изменилась техника исполнения – мастерицы оказывали предпочтение «глади» и «крестику». Популярными оставались растительные мотивы, с преобладанием цветочных композиций, составленных из пышных роз и элементов местной флоры, в яркой полихромной гамме. До настоящего времени у татар в сельской местности бытует обычай украшать гостевую комнату белыми подушками с вышитыми на них крупными яркими розами, маками, колокольчиками и васильками.

В далеком прошлом осталось массовое распространение тамбурной вышивки и ушковой техники, отличающих татарских мастериц. Современную ушковую технику, эпизодически воспроизводящуюся по заданным стандартным образцам, взятым из средств массовой информации, невозможно сопоставить с искусным своеобразием работ потомственных татарских вышивальщиц XIX века. На этом фоне творчество З.Н. Бикташевой (1955 г.р.), владеющей как профессиональными навыками художника, так и умением применять аутентичную ушковую технику, а также стилевые особенности народной вышивки, способствует сохранению и развитию этого традиционного для татар вида народного искусства. З.Н. Бикташева, родилась в семье известного татарского художника-портретиста Наки Бикташева. Она росла в творческой атмосфере и воспитывалась на подлинных образцах татарской культуры. В 1974 г., окончив Казанское художественное училище, поступила в мастерскую своего отца, где под его руководством работала до 1984 года. Овладев профессиональными навыками художника-живописца, З.Н. Бикташева на новом уровне обратилась к народному искусству татар, стала углубленно изучать стилевые особенности и виды самобытных техник татарских вышивок. Рассматривая ее работы, словно слышишь традиционную татарскую мелодию. Образы растений, цветов и птиц в творчестве художницы, как и в народном искусстве, являются не только изображениями из мира флоры и фауны, они наделяются определенным значением и воспроизводят общепринятые в тюркском мире символы.

«Золотая птица – Хумай над Булгарами» привлекает праздничным великолепием. Роскошная птица, держащая в клюве мифический комочек земли, подобно знаменитой булгарской уточке, воспринимается как райское создание. Однако, безукоризненная гармония под силу лишь Создателю. В обыденном мире никто не вправе претендовать на совершенство своих произведений. Соблюдая этот неписаный закон, З.Н. Бикташева внесла в композицию работы намеренную «неправильность». Асимметричность – одно из свойств художественной выразительности в татарском искусстве, художница сочетает с симметричным построением. Единство этих двух противоположностей, как выражение дуалистического миропонимания свойственного тюркским народам, не случайно стало для З.Н. Бикташевой основным композиционным принципом. Темно-синий фон

# ЧИГҮ ҺӨНӘРЕ

З.Н. Бикташева һәм Л.Ф. Фәсхетдинованың хезмәтләре татар халкында чигү һәм кул эшләренең киң таралган булуын тагын бер кат раслый. Хәзерге чигү осталарының һөнәри үсешенә XIX–XX гасырларда башкарылган, музей яисә шәхси коллекцияләрдә саклanган үзенчәлекле чигү үрнәкләре йогынты ясый. Әлеге үрнәкләр мәрҗәннәр, сәйлән, алтын җепләр белән бизәкләп чигелгән калфаклардан, шулай ук тырнак алмалау, тамбур техникасы белән күпертеп чәчәк төшерү, төрле тасмалар кулланып бизәкләнгән баш киемнәреннән, нәфис шома чигү, сабак җөе, декоратив текстиль төрләрендә башкарылган үрнәкләрдән гыйбарәт. Элеккеге осталарның хезмәтләре ачык палитрадагы үсемлек-чәчәк формалары, ассиметрик композицияләрдә башкарылган. Алар барысы да күңелгә бәйрәм рухы өсти.

Чигү сәнгате Инкыйлаб, Гражданнар һәм Ватан сугышлары чорларында онытылып тора. Шулай да, кызга бирнә әзерләү традициясе татарларда чигү эшенең сакланып калуына китерә. 1950–1960 елларда чигү һөнәренә мөрәҗәгать итү тагын көчәеп китә. Барлык җирләрдә диярлек чигү техникасы үзгәрә, кул эшләре осталары нәфис шома чигү һәм тапкырлап чигү техникаларын кулай күрәләр. Ачык төсләр ярдәмендә җирле флораны сурәтләгән үсемлек мотивларын чагылдырган чәчәк композицияләре популярлаша. Хәзерге көндә дә авыл җирлегендә яшәүче татарлар кунак бүлмәләрен ачык төсләрдәге эре гөлчәчәк, мәк, кыңгырау һәм күк чәчәкләр чигелгән мендәрләр белән матурлыйлар.

Татар чигү осталарын аерып торган тамбур һәм тырнак алмалау техникаларының киң кулланылышы үткәндә калып бара. Төрле массакүләм мәгълүмати чараларда бирелгән хәзерге тырнак алмалау техникасын калыплар, үрнәкләр буенча яңартуны исә XIX йөз татар чигү осталарының үзенчәлекле һәм нәфис хезмәтләре белән чагыштырып булмый, әлбәттә. Шушы фонда З.Н. Бикташева иҗаты (1955 елда туган) татар халык милли сәнгатенең саклануы һәм үсеше өчен аеруча әһәмиятле урын били. Профессиональ рәссам, шул ук вакытта, татар милли чигү һөнәренең стиль үзенчәлекләрен яхшы белүче тырнак алмалау техникасын да үзләштерә. З.Н. Бикташева танылган татар рәссамы, портрет остасы Нәкый Бикташев гаиләсендә туып үсә. Ул иҗади җирлектә үсеп, чын татар милли сәнгате үрнәкләрендә тәрбияләнә. 1974 елда Казан сәнгать училищесын тәмамлап, үз әтисенең остаханәсенә эшкә керә, анда 1984 елга кадәр хезмәт куя. З.Н.Бикташева, профессиональ рәссам һөнәрен үзләштереп, татар халкының милли сәнгатенә мөрәҗәгать итә, татар чигү һөнәренең үзенчәлекле төрләрен һәм стиль үзенчәлекләрен тирәнтен өйрәнә. Аның хезмәтләренә күз төшерсәң, татар милли көйләрен ишеткәндәй буласың. Сәнгатькәр сурәтләгән үсемлек, чәчәк, кошкорт образлары әйләнә-тирә дөньяны тасвирлап кына калмыйча, төрки дөньяның символлары буларак та аерым әһәмияткә ия.

«Алтын Һомай кошы Болгар өстеннән очып бара» хезмәте үзенең бәйрәмчә зәвыклылыгы белән игътибарны җәлеп итә. Купшы кош томшыгына туфрак капкан болгар үрдәге, җәннәт кошы буларак кабул ителә. Әмма төп гармонияне урнаштыру бары тик Аллаһ кодрәтенндә генә. Гадәти тормыштан З.Н. Бикташева асимметрия ысулын кертеп җибәрә, ул симметрик төзелеш белән берләштерелә. Төрки халыклар өчен хас булган әлеге ике ысулның бердәмлеге З.Н. Бикташева өчен төп композицион принципка әйләнә. Куе зәңгәр төстәге очсыз-кырыйсыз һәм мәңгелек күк фоны ачык төстәге Һомай кошының һәм чәчәккә күмелгән тормыш агачының контрастында бирелә. Полихром палитрада зәңгәр, яшел, шәмәхә һәм ак төсләргә өстенлек бирелә. Мәчет сурәте, зооформ стилендә башкарылган савыт, халык язмышын символлаштырган агачның тамырына тереклек суы җибәрүче чүлмәк – барысы да Болгар шәһәрен гәүдәләндерә. З.Н. Бикташева үз авторлыгын традицион чия агачы чәчәкләре белән раслый.

Түбәндә XIX гасыр чигү осталарының кул эшләре үрнәкләре белән З.Н. Бикташеваның тырнак алмалау техникасында башкарылган хезмәтләре чагыштырып карала.

вечного и бескрайнего неба подчеркивает абрис птицы Хумай и цветущего древа жизни, выполненного в ярком, контрастном колористическом решении. В полихромной палитре основными красками служат синий, зеленый, фиолетовый и белый. Город Булгар олицетворяют силуэт мечети, сосуд, декорированный в типичном зооморфном стиле и кувшин, из которого льется живая вода на корень древа, символизирующего судьбу народа. Свое авторство З.Н. Бикташева традиционно обозначила цветками вишни.

Ниже приводятся образцы ушковой техники неизвестной мастерицы XIX в. и З.Н. Бикташевой. Сопоставление свидетельствует о преемственности.



**З.Н. Бикташева,** 1955 г.р.
Фрагмент панно «Птица-весна», 2016
Тамбур, аппликация, вышивка, ушковая техника
*Собственность автора*

**З.Н. Бикташева** (1955 елда туган)
«Яз кошы» панно фрагменты, 2016
Тамбур, аппликация, чигү, тырнак алмалау техникасы.
*Авторның шәхси милке*



**Неизвестный мастер**
Фрагмент головного убора, XIX век
Парча, шелк, бархат, бисер, мишурная нить, аппликация, вышивка, ушковая техника
*Собрание НМ РТ*

**Билгесез оста**
Баш киеме фрагменты, XIX гасыр
Парча, ефәк, бәрхет, сәйлән, мишура җебе, аппликация, чигү, тырнак алмалау техникасы
*ТР Милли музее җыелмасы*

Уникальная вышивка Л.Ф. Фасхутдиновой (1968 г.р.) является образцом высокого национального искусства. Художница, творчески переработав опыт народных мастериц, создала ряд искусных произведений в индивидуальной манере. Ее работа «Тюркский ковер» (2016) демонстрировала традиционные виды татарской ручной вышивки. В композицию декора изделия вошли розетки: солярные и цветочные, завихренные и окруженные прямыми лучами или лепестками, а также концентрические круги и меандры, несущие семантическое значение.

Л.Ф. Фасхутдинова была хорошо знакома с народными традициями благодаря бабушке, у которой часто гостила в деревне. Уже в раннем возрасте ее внимание привлекали яркие вышитые изделия, украшающие интерьер татарского дома. За годы обучения в Казанском художественном училище им. Н.И. Фешина (1984–1988) Л.Ф. Фасхутдинова получила отличную профессиональную подготовку. Решила освоить искусство вышивки и поехала (по приглашению) в Бухару, старейший известный центр золотого шитья. Продолжая заниматься избранным делом вернувшись на родину, художница в совершенстве освоила секреты татарской вышивки. Она владеет всеми видами швов и искусно применяет устойчивые в декоративной системе татар орнаментальные мотивы.

Шулай ук Л.Ф. Фәсхетдинованың (1968 елда туган) чигү эшләре дә татар милли сәнгатенең югары үрнәге булып санала. Ул, элекке буыннар осталарының тәҗрибәсен үзенчәлекле кулланып, төрле нәфис бизәкләр барлыкка китерә. Экспозициядә урын алган «Төрки келәм» хезмәте татар кул чигешенең традицион төрен чагылдыра. Чигү үрнәге композициясе розеткалар – соляр һәм чәчәк, төрле сыгылмалы сызыклар, нурлар һәм таҗлар белән бизәкләнә, түгәрәкләр һәм менандрлар белән баетыла. Татар милли сәнгате өчен хас булган орнамент мотивлары кулланыла.



**Марфуга**, конец XIX в.
Фрагмент намазлыка – молитвенного коврика, начало XX в.
Саржа, шелковые нити, тамбурный шов
Частная коллекция, с. Новая Мочалеевка
*Из материалов экспедиции ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ в Самарскую область 2015 г.*

**Мәрфуга**, XIX гасыр азагы
Намазлык фрагменты, XX гасыр башы
Саржа, ефәк җепләр, тамбурлы җөй
Шәхси коллекция
*Яңа Мунчалы, 2015 елда Самара өлкәсенә оештырылган ТӘһСИ экспедициясе материалларыннан*



**Л.Ф. Фасхутдинова**, 1968 г.р.
Фрагмент «Тюркского ковра», XXI в.
Шерсть, тамбурный шов
*Собственность автора*

**Л.Ф. Фәсхетдинова** (1968 елда туган)
«Төрки келәм» фрагменты, XXI гасыр
Йон, тамбурлы җөй
*Авторның шәхси милке*

# ЮВЕЛИРНОЕ ИСКУССТВО

Внимание посетителей выставки «Алтын кош – Золотая птица» привлекали к себе ювелирные украшения Р.Х. Ахметова (1968 г.р.), Т.В. Соловьевой (1966 г.р.) и А.С. Шамсутдинова (1963 г.р.), использующих технику зернь, известную ювелирам Среднего Поволжья периодов Булгарского государства, Золотой Орды, Казанского ханства и Казанской губернии, где она применялась в сочетании с филигранью. Изделия татарских мастеров отличались инкрустацией полудрагоценными камнями: бирюзой, сердоликом, кораллами, горным хрусталем и др. Развитие ювелирного искусства у татар тесно связано с национальной традицией украшать женский наряд. Оно процветало по начало XX столетия. Угасание было обусловлено как европеизацией костюма, так и запрещением частного ювелирного дела в советское время.

В середине XX века в Казани и Шемордане (Сабинский р-н) началось возрождение производства традиционных татарских украшений, длящееся до конца 1980-х годов. Процесс был прерван в период перестройки, но затем возобновился, чему способствовали развитие частного предпринимательства и организация Палаты ремесел в Татарстане, объединяющих как профессиональных художников, так и самодеятельных мастеров. В списке Центра развития народных художественных промыслов и ремесел значатся ювелиры: Т.В. Соловьева, закончившая Чебоксарское художественное училище (1986) и А.С. Шамсутдинов, не получивший специального образования. Оба мастера являются продолжателями народных традиций. Сопоставляя их произведения, следует отметить, что авторские работы отличаются уровнем художественного замысла и воплощения. Так, комплекты «Птица» и «Желтые тюльпаны» Т.В. Соловьевой характеризуются более изысканным вкусом и выразительностью созданных образов. В то же время реконструкция изделий им удается в равной степени виртуозно. В данной области они оба вносят достойный вклад в сохранение самобытного ювелирного искусства татар.

В номинации «Авторский проект. Ювелирное искусство», победителем стал Р.Х. Ахметов (1968 г.р.). Ювелирный комплект его работы включает подвеску на цепочке и серьги, выполненные в форме трилистника, обрамленного изящными вьющимися изгибами стилизованного стебля. Подвеска состоит из антропоморфной фигурки, заключенной в центре волнообразного сквозного узора. Мастер создал образ Умай, в технике металлопластики, воплотив богиню в трехрогой короне. Плавные изгибы цветочных узоров из металла олицетворяют оберегающие силы земной и космической природы. Художественное решение связано с распространенным в народном творчестве орнаментальным мотивом – цветущим древом жизни, олицетворяющим богиню. За спиной богини мастер изобразил раскинутые крылья. Про счастливого человека тюрки говорили: «Над ним пролетела тень Хумай-птицы». В руках Хумай Р.Х. Ахметов изобразил чашу, содержащую влагу вечно зарождающейся жизни – символ богатства семьи, племени, народа. Особую выразительность изделию придает отделка из бирюзы и коралла, создающая впечатление капелек росы в лучах восходящего солнца.

Малочисленность ювелиров-участников показала, что в настоящее время татарское ювелирное искусство в русле народных традиций развивается недостаточно, а потому требует поддержки на государственном уровне.



**Неизвестный мастер, XIX в.**
Фрагмент накосника
Серебро, сердолик, скань, зернь
*Коллекция школьного музея с. Зюри*
*Из материалов экспедиции ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, Мамадышский р-н РТ. 2014 г.*

**Билгесез оста, XIX гасыр**
Чулпы фрагменты
Көмеш, сердолик, челтәрләү, бөртекләү
*Җөри авылының мәктәп музее коллекциясе*
*2014 елда Татарстанның Мамадыш районына оештырылган ТӘһСИ экспедициясе материалларыннан*

# ЗӘРКӘНЧЕЛЕК

«Алтын кош – Золотая птица» күргәзмәсен карарга килүчеләрнең игътибарын, шулай ук, Р.Х. Әхмәтов, А.С. Шәмсетдинов һәм Т.В. Соловьева тарафыннан иҗат ителгән зәркән эшләнмәләр дә җәлеп итте. Алар Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы һәм Казан губернасы чорларыннан ук Урта Идел буе зәркән осталарына билгеле булган бөртекләү техникасында башкарылган.

Татар зәркәнчеләренең эшләнмәләре фирәзә, сердолик, коралл, хрусталь һ.б. ярымасылташлар белән бизәлгән. Татарларда зәркәнчелекнең үсеше XX башына кадәр киң таралган булуы хатын-кыз киемнәрен бизәү белән бәйле. Әмма, Европага ориентирлашу сәбәпле, Советлар заманында шәхси зәркәнчелек белән шөгыльләнү тыела төшә.

XX гасырның урталарында (1980 елларга кадәр) Казан шәһәре һәм Шәмәрдән бистәсендә (Саба районы) татар милли бизәнү әйберләрен яңадан торгызу башлана. Үзгәртеп кору заманында бу процесс өзелә, соңыннан әлеге эшчәнлек тагын яңартыла. Һәм ул шәхси эшмәкәрлек, Татарстандагы һөнәрчелек палатасының үсешенә этәргеч була. Милли сәнгать һөнәрләре үзгендә түбәндәге зәркәнчеләр теркәлгән: Т.В. Соловьева (1986 елда Чабаксар сәнгать училищесын тәмамлаган) һәм А.С. Шәмсетдинов (махсус һөнәри белемсез). Осталарның икесе дә халык традицияләренең дәвамчылары булып торалар. Авторларның иҗат җимешләре үзләренең сәнгати бирелеше белән югары дәрәҗәдә эшләнгән булулары белән аерылып торалар. Мәсәлән, Т.В. Соловьеваның «Кош», «Сары лаләләр» комплектлары үзләренең югары зәвыклы булулары һәм сәнгатьлелекләре белән аерылып торалар. Шул ук вакытта эшләнмәләрнең реконструкциясе дә әлеге ике зәркәнче тарафыннан бик оста башкарылган. Осталарның икесе дә әлеге өлкәдә татар халкының зәркәнчелеген саклау юнәлешендә зур өлеш кертәләр.



**А.С. Шамсутдинов,** 1963 г.р.
Фрагмент колье, 2016 г.
Серебро, сердолик, бирюза, скань, зерньь
*Собственность автора*

**А.С. Шәмсетдинов** (1963 елда туган)
Муенса фрагменты, 2016 ел
Көмеш, сердолик, фирәзә, челтәрләү, бөртекләү
*Авторның шәхси милке*

«Автор проекты. Зәркәнчелек сәнгате» номинациясендә Әхмәтов Ринат Хәмитлатыйф улы (1968 елда туган) җиңү яулады. Бәйгедә аның тукранбаш һәм стильләшкән нечкә сыгылмалы ботак формасындагы чылбыр, асылмадан һәм алкалардан торган зәркән комплекты катнашты. Асылма дулкынсыман бизәкнең уртасына урнашкан антроморф фигураны тәшкил итә. Оста Умайны металл-пластика аша сәнгатьчә тасвирлауга ирешә, ул өч таҗлы алиһә буларак тасвирлана. Җир һәм галәмнең табигый көчен иҗат остасы чәчәк үрентеләренең сыгылмалыгы аша сурәтли. Алиһәнең гәүдәләнеше буларак тасвирланган тормыш агачы халык иҗатында киң кулланылган бизәкләү мотивлары үрнәкләрендәге чишелешкә ия. Алиһә җәелгән канатлар белән тасвирланган. Төркиләр бәхетле кеше хакында «Аның өстеннән Һомай кошы очып үткән» дип әйтә торган булганнар. Оста мәңгелек яшәеш – алиһә кулындагы касәне гаилә, кабилә, нәсел байлыгы символы буларак гәүдәләндергән. Эшләнмәнең фирәзә һәм коралл белән бизәлүе кояш нурларында җемелдәүче чык тамчыларын хәтерләтә.

Хәзерге вакытта татарларда милли традицияләргә нигезләнгән зәркәнчелек сәнгате онытылып бара, бу өлкәдә хезмәт куючы осталар аз санда, бүген әлеге сәнгатьне торгызу һәм үстерү дәүләт ярдәменә мохтаҗ.

# РЕЗЬБА ПО ДЕРЕВУ

Р.Х. Ахметов стал победителем во второй номинации «Авторский проект. Ювелирное искусство» и «Авторский проект. Художественная обработка дерева». Резьба по дереву привлекала будущего художника с юности, окончив Казанское художественное училище им. Н.И. Фешина (1989), он благодаря долгой практике и разнообразным экспериментам разработал свою авторскую трудоемкую технологию, соединяющую дерево и металл. Мастер продолжает традиции самобытной резьбы, известной пратюркам более тысячи лет и являющейся неотъемлемой частью народной культуры татар. Р.Х. Ахметов выработал свой индивидуальный стиль, особенностью которого стало сочетание объемной формы и детальной проработки сюжетных образов. Мастера привлекают национальные темы, включающие древние и современные обычаи татарского народа. Трехчастная структура работы «Мифы древней Булгарии» отражает три мощных культурных пласта в исторической судьбе татар. Для воплощения замысла художник выбрал крупный формат. Произведение, выполненное в технике плоскорельефной резьбы, олицетворяет аутентичные эстетические ценности, органично связанные с идеей конкурса.



**Р.А. Насыбуллин,** 1934 г.р.
Фрагмент сундука, 1955
Плоскорельефная резьба
*Частная коллекция, с. Елховый куст*
*Из материалов экспедиции в Ульяновскую область. 2018 г*

**Р.А. Насыйбуллин,** 1934 елда туган
Сандык фрагменты, 1955
Яссы рельефлы кисем
*Шәхси коллекция, Зирекле Куак авылы*
*Ульяновск өлкәсендә үткәрелгән экспедиция материалларыннан, 2018 ел*

# АГАЧНЫ УЕП БИЗӘКЛӘҮ

Р.Х. Әхмәтов «Автор проекты. Агачны уеп бизәкләү» номинациясендә җиңүче булып чыкты. Аны балачактан ук агачны кисеп бизәкләү һәм металл белән эшләү кызыксындыра. Н.И. Фешин исем. Казан сәнгать училищесын тәмамлаганнан соң, ул материал һәм аерым технологияләр ярдәмендә төрле экспериментлар уздыра. Оста борынгы төрки әби-бабаларыбызга мең еллар элек билгеле булган татар милли мәдәниятенең аерылгысыз өлеше саналган агачны кисеп, уеп бизәкләүнең үзенчәлекле традицияләрен дәвам итә. Иҗат әһеле үзенең күләмле форма, шул ук вакытта детальләрнең зәркәнчә нәфис эшләнешен берләштергән аерым стилен үстерә. Аның әсәрләре үзләренең композицион бөтенлеге һәм пропорцияләренең гармоник бирелеше белән аерылып тора. Р.Х. Әхмәтов аеруча татар халкының борынгы һәм хәзерге гореф-гадәтләрен, йолаларын яктырткан тема һәм милли сюжетларны яратып иҗат итә.

«Борыгы Болгар мифлары» хезмәтенең өч өлешле структурасы татар халкының тарихи үткәнендәге өч төп мәдәни катламны билгели. Үзенең теләк-ниятләрен тормышка ашыру өчен автор зур форматны сайлап ала.

Яссы рельефлы агачны кисеп, уеп бизәкләү техникасында башкарылган әсәр аутентик эстетик кыйммәткә ия һәм ул бәйгенең тематикасына һәм идеясенә органик рәвештә үрелеп китә.

**Р.Х. Ахметов,** 1968 г.р.
Фрагмент панно «Мифы древней Булгарии», 2017
Плоскорельефная резьба
*Собственность автора*

**Р.Х. Әхмәтов,** 1968 елда туган
«Борынгы болгар мифлары» панносы фрагменты, 2017 ел
Яссы рельефлы кисем
*Авторның шәхси милке*



# КОЖАНАЯ МОЗАИКА

Сохранившиеся образцы татарской кожаной мозаики датируются с середины XVIII по середину XIX века. Данная техника изготовления существовала в форме сельского и городского ремесла, восходящего истоками к культуре волжских булгар. К концу XIX в. производство шло уже на уровне промыслов, просуществовавших до начала XX столетия. Кожаная мозаика, вышитая по контуру узора нитками разных цветов, украшала сапожки, подушки и другие предметы быта. Производство изделий, сшитых встык вручную из кусочков разноцветной кожи, возродилось в 1960-е годы. В настоящее время одним из известных мастеров в Республике является А.А. Замилова, которая преподает с 2002 года в Казанском художественном училище им. Н. Фешина, передавая свои знания студентам. Также в экспозиции были представлены работы Н.Х. Кумысниковой, признанного мастера в этой области, соблюдающей традиционные эстетические каноны в авторской интерпретации.



**Неизвестный мастер, XIX в.**
Фрагмент сапога
Кожаная мозаика
*Частная коллекция*
*Из материалов экспедиции ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, Мамадышский район РТ. 2014 г.*

**Билгесез автор**
Читек фрагменты. Күн мозаикасы
*Шәхси коллекция*
*2014 елда Татарстанның Мамадыш районына оештырылган ТӘһСИ экспедициясе материалларыннан*

# КҮН МОЗАИКАСЫ

Татар күн мозаикасы техникасында эшләнгән сакланып калган үрнәкләре XVIII–XIX гасыр урталарына карый. Идел буе болгарларының мәдәниятенә барып тоташкан, авыл җирләрендә һәм шәһәрдә кулланылган күн мозаикасы XIX гасырларда профессиональ һөнәрчелеккә әйләнеп, XX гасыр башларына кадәр киң таралыш ала. Күн мозаикасы ярдәмендә контур буенча төрле төстәге җепләр белән чигелгән аяк киемнәрен, мендәр тышларын һәм башка көнкүреш әйберләрен күп очратырга була. Төрле төстәсе тире һәм күн кисәкләреннән кулдан тегелгән әйберләр җитештерү 1960 елларда кабат торгызыла. Хәзерге вакытта әлеге өлкәдә иң танылган осталардан Ә.Ә. Җәмилованы әйтергә була. Ул, 2002 елдан башлап, Н. Фешин исемендәге сәнгать училищесында студентларны үз һөнәренә өйрәтә һәм үз дәвамчыларын үстерә. Шулай ук әлеге төр һөнәрнең танылган остасы Н.Х. Кумысникованың хезмәтләре дә күргәзмәдә урын алды. Алар этник кануннар нигезендә автор фантазиясе белән баетылган.



**Н.Х. Кумысникова,** 1958 г.р.
Фрагмент панно «Осень», 2012
Кожаная мозаика
*Из коллекции Государственного историко-архитектурного и художественного музея-заповедника «Казанский Кремль»*

**Н.Х. Кумысникова,** 1958 елда туган
«Көз» панносының фрагменты
*«Казан Кремле» Дәүләт тарих, архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы коллекциясе*

# КЕРАМИКА

Керамика, являясь одним из традиционных видов народного искусства у далеких предков татар, развивалась и формировалась под воздействием стилевых канонов Степи и салтово-маяцкой культуры. Об этом свидетельствуют булгарские сосуды, декорированные зооморфными стилизованными изображения в технике лепной мелкой пластики.

Стилевые особенности татарского народного искусства изучала и воспроизводила их в отделке образцов для выпускаемой сувенирной продукции Н.В. Кузьминых (1956 г.р.), работавшая дизайнером на Комбинате народных художественных промыслов в Казани после окончания Казанского инженерно-строительного института (1980). Будучи сотрудником Художественного фонда Республики Татарстан (1988–1994), выполняла работы для интерьеров общественных помещений и ландшафтного дизайна. Н.В. Кузьминых является признанным мастером керамики, мелкой пластики, рассчитанной на восприятие с близкого расстояния и, следовательно, предполагающей детальную проработку. Мастер, используя лаконичные выразительные средства обработки глины, создает собирательные образы, передающие глубину авторских замыслов, связанных с вечными ценностями.

